БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 ноябрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 18

**Балтач муниципаль районының муниципаль предприятиеләрен һәм учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Балтач районы прокуратурасының 2025 елның 23 сентябрендәге 02-08-01-2025/Прдп359-25-20920011номерлы протестын карап, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында», «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законнарга яраштырып һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Балтач район Советының 2010 елның 2 апрелендәге 174 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районының муниципаль предприятиеләрен һәм учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы Нигезләмәгә (2012 елның 15 ноябрендәге 134 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Коммерциягә карамаган оешма мөлкәтен акчалата һәм башка рәвешләрдә формалаштыру чыганаклары булып түбәндәгеләр тора:

- гамәлгә куючылардан (катнашучылардан, әгъзалардан)даими һәм бер мәртәбә кертемнәр;
- ирекле мөлкәт кертемнәре һәм иганәләр;
- товарлар, эшләр, хезмәтләр сатудан кергән табыш;
- акцияләр, облигацияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр һәм кертемнәр буенча алына торган дивидендлар (керемнәр, процентлар);
- коммерциягә карамаган оешма милкеннән алына торган керемнәр;
- «Торак төзелешен үстерүгә, туристлык инфраструктурасы объектларын булдыруга һәм территорияләрне башкача үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161- ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 4.3 өлешендә каралган акчалар керүе;
- унитар предприятиегә хуҗалык алып бару хокукында яисә әлеге мөлкәтнең милекчесе белән оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт;
- унитар предприятиенең үз эшчәнлегеннән кергән керемнәре;
- законнарга каршы килми торган башка чыганаклардан закон белән тыелмаган башка керемнәр.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов